# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 15 ноябре** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында : «I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Карашай-Саклау торак пунктларын төзекләндерү ,халыкның күпләп ял итү урыннарын кору (Сабантуй милли бәйрәмен үткәрү урынын койма белән әйләндереп алу һәм төзелеш материаллары сатып алу, «Хәтер бакчасы» паркын койма белән әйләндереп алу өчен әзер коймалар сатып алу ) ;

2. Карашай-Саклау авылындагы махсус күмү урыннарын төзекләндерү (биек агачларны йолкыту, куаклардан чистарту очен махсус аренда.техника яллау )

3. Карашай-Саклау торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

4. Карашай Саклау авылында көнкүреш калдыклары, чүп-чарлар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру һәм чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү, махсус техника яллау )

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева